ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**гражданка Р.Н. Садыйкованың Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацлары һәм 3.5 пунктының икенче абзацы белән, аны рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча күрсәтелгән карар белән, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаяте буенча**

Казан шәһәре 2020 елның 11 марты

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Р.Н. Садыйкова шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.Н. Садыйкова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның

14 февралендәге 97 номерлы (2019 елның 7 мартындагы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацлары һәм 3.5 пунктының икенче абзацы белән, аны татар телендә рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча күрсәтелгән карар белән, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 307 номерлы карары) 2 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Тәртипнең 3.1 пунктындагы икенче абзацы, территориаль социаль яклау органы, эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көнлек срокта, шифаханә дәвалавы профиле буенча юлламалар (юлламалар керү турында мәгълүмат) кергән көннән, чират буенча, гражданнарга шифаханә дәвалау профиле буенча юлламалар керү һәм әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта яңарту кирәклеге турында хәбәр итә (гамәлдә булу вакыты чыккан очракта) (2019 елның 26 сентябрендәге редакциясендә) дип билгели.

Тәртипнең 3.1 пунктындагы бишенче абзацы нигезендә территориаль социаль яклау органы, граждан тарафыннан бирелгән һәм территориаль орган тарафыннан яңартылган документлар һәм белешмәләр алынганнан соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә, юллама бүлеп бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында гражданга почта аша яисә гражданның теләге буенча гаризада күрсәтелгән алымнарның берсе (телефон, йә СМС-хәбәр, йә электрон почта) аша хәбәр итә.

Тәртипнең 3.5 пунктының икенче абзацы нигезендә әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы булмаган документлар пакеты тапшыру (аларның гамәлдә булу вакыты чыккан очракта),

гражданга юллама бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора (2019 елның 26 сентябрендәге редакциясендә).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 307 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацы белән шифаханә-курорт оешмаларында шифаханә-курорт дәвалавы дәвамлылыгын билгели торган Тәртипнең 1.5 пунктында «18 көн» сүзләре «14 календарь көне» сүзләренә алмаштырылган.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, гражданка Р.Н. Садыйкова 2017 елдан пенсионер. Шул ук елда ул Казан шәһәре Идел буе районы социаль яклау бүлегенә карала торган Тәртип нигезендә ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән, аны 2019 елда алган. Дәгъва белдерелә торган Тәртип нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары бозылуны мөрәҗәгать итүче анда каралган чиратлылык принцибының гражданнарга шифаханә дәвалавы профиле буенча юлламалар керү һәм Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта яңарту кирәклеге турында хәбәр итүгә генә кагылуында күрә. Аның фикеренчә, юллама бирү турында карар кабул итүгә әлеге принцип туры килми. Шул рәвешле, ул санаганча, дәгъва белдерелә торган нормалар аларның үзара бәйләнешендә чиратлылык принцибын юллама бүлеп бирү турында карар кабул итү процедурасында кулланмыйлар, мондый хәбәр итү ысулын билгеләмиләр (Тәртипнең 3.1 пунктындагы икенче абзацы) һәм бары тик, Тәртипнең 2.2.2 пунктында каралганча, юллама бирү турында кабул ителгән карар турында яисә аны бүлеп бирүдән баш тарту турында гражданга хәбәр итәләр. Шул ук вакытта ул, Тәртипкә 2 нче кушымтадагы форма буенча гаризада гражданнар шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә куелганда гына үзләренә хәбәр итү ысулын сайлый, дип басым ясый. Аның фикеренчә, шифаханәдә дәвалану профиле буенча юлламалар кергән очракта һәм тиешле документларны яңарту кирәк булганда гражданнарга хәбәр итү ысулы социаль яклау территориаль органының ирекле каравына калдырылган. Шуның белән, ул санаганча, дәгъва белдерелә торган нормалар аның конституциячел

хокукларын боза, чөнки карала торган хокукый җайга салуларда гражданнарга шифаханә дәвалавы профиле буенча юлламалар керү турында хәбәр итү ысулы һәм документларның гамәлдә булу вакыты чыга торган яки инде чыккан булса, аларны яңарту срогы тиешенчә җайга салынмаган.

Гражданка Р.Н. Садыйкова шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 307 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацы белән Тәртипнең 1.5 пунктында шифаханә-курорт оешмаларында шифаханә-курорт дәвалавы дәвамлылыгы 18 көннән 14 календарь көненә кадәр кыскартылган, бу гражданнарның социаль тәэминатка конституциячел хокукларын чикләү булып тора, дип күрсәтә.

Моннан тыш, аның раславы буенча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы»нда да, «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы»нда да, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда да татар телендә басылып чыкмаган (урнаштырылмаган). Аны татар телендә бастырып чыгармау аның Татарстан Республикасы Конституциясенең 34 статьясы белән гарантияләнгән туган телдән файдалануга конституциячел хокукын боза һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 статьясында билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт телләренең тигез хокуклылыгы принцибына каршы килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Р.Н. Садыйкова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацларын һәм 3.5 пунктының икенче абзацын, татар телендә рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча күрсәтелгән карарны, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

карарының 2 пунктындагы икенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 8, 13, 24 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 34 (икенче өлеш), 38 (беренче өлеш) һәм 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның, шул исәптән гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләре буенча, кабул итү, нәшер итү, имзалау, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен билгели.

«Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары рус телендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» басмасында — 2011 елның 11 маендагы 18 номерында, 0663 ст., ә татар телендә 2019 елның 12 ноябрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылган.

Гавами хакимият органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсми бастырып чыгару тәртибенә кагылышлы мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституция судының тикшерү предметы булып торган иде инде, ул 2017 елның 23 июнендәге 74-П номерлы карарында Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә генә норматив хокукый акт текстын рәсми бастырып чыгару аны рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану өчен үзеннән-үзе җитәрлек нигез дип санала алмый, чөнки бу гражданнар тарафыннан карала

торган туган телдә хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый актның эчтәлеге белән танышу мөмкинлеген гамәлгә ашыру өчен объектив каршылыклар тудырмый дигән нәтиҗәгә килде.

Шулай итеп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карарының татар телендә рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы (дүртенче өлеш) һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр буенча һәм судлар таләпләре буенча Татарстан Республикасы законының яисә аның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты, шулай ук җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының конституциячеллеген тикшерә. Шуңа күрә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацлары һәм 3.5 пунктының икенче абзацы, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче

абзацы Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә карап тикшерелергә мөмкин.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 статьясындагы беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына конституциячел хокукларның һәм ирекләрнең бозылуына карата шикаять белән Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән хокуклары һәм ирекләре бозылган гражданнар һәм аларның берләшмәләре мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Шул ук вакытта, әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса; закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы буенча Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була. Шуңа бәйле рәвештә шикаятькә кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләре «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 статьясындагы икенче өлеше нигезендә дәгъвалана торган нигезләмәләрнең мөрәҗәгать итүченең конкрет эшен хәл иткәндә кулланылуын раслый торган итеп каралырга мөмкин.

Шулай итеп, шикаять тиешле мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясында билгеләнгән шикаять бирү таләпләренә туры килә һәм аны Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга алудан баш тарту өчен нинди дә булса нигезләр юк.

4. Татарстан Республикасы Конституция судына шикаять биргәндә, ул пенсионер, инвалид бала тәрбияләүче һәм авыр матди хәлдә булганга күрә,

гражданка Р.Н. Садыйкова тарафыннан үзен дәүләт пошлинасын түләүдән азат итү турында үтенеч белдерелгән.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 42 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткәндә дәүләт пошлинасы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә алына.

Россия Федерациясе Салым кодексының 333.23 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Россия Федерациясе субъектларының Конституция (устав) судлары, түләүченең матди хәленнән чыгып, аны күрсәтелгән судларда карала торган эшләр буенча дәүләт пошлинасын түләүдән азат итәргә йә аның күләмен киметергә, шулай ук әлеге Кодексның 333.41 статьясында каралган тәртиптә аны түләүне кичектереп торырга (өлешләп түләргә) хокуклы.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданка Р.Н. Садыйкова үтенечен канәгатьләндерергә һәм аны дәүләт пошлинасын түләүдән азат итәргә мөмкин дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлешенә, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 42 статьясына, 45 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 51 статьясындагы беренче өлешенә, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Гражданка Р.Н. Садыйкова шикаятен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең, татар телендә рәсми бастырып чыгару

тәртибе буенча, конституциячеллеген тикшерү өлешендә карауга алудан баш тартырга, чөнки әлеге өлештә ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 3.1 пунктындагы икенче һәм бишенче абзацлары һәм 3.5 пунктының икенче абзацы белән, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 маендагы 307 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Р.Н. Садыйкова шикаятен карауга кабул итәргә.

3. Гражданка Р.Н. Садыйкова үтенечен канәгатьләндерергә һәм аны дәүләт пошлинасын түләүдән азат итәргә.

4. Кабул ителгән карар турында якларга — гражданка Р.Н. Садыйковага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына хәбәр итәргә.

5. Бу эш буенча докладчы судья итеп Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы Р.Г. Сәхиеваны билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан әлеге эшне карап тикшерү көнен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында эшләрне тыңлау чираты тәртибендә билгеләргә.

7. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 4-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**